| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2020 п.г.т.Алексеевское № 146

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс уздыру турында**

Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны стимуллаштыру һәм авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен бүләкләүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 135, 191 маддәләре нигезендә

**карар кылам:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) конкурсын уздыру турында Нигезләмәне (Кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Леденцов О.Н.) әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам, конкурсны уздыру тәртибен тикшереп торуны, аңа йомгак ясауны авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Г.К. Мусинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 27 апрелендәге
146 номерлы карарына
кушымта

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс уздыру турында**
**Нигезләмә**

1. Конкурс Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләрен уздыру барышында югары күрсәткечләргә ирешкән иң актив механизаторларны мотивацияләү максатларында уздырыла.

Конкурс язгы кыр эшләре вакытында агымдагы елның 01 апреленнән 01 июненә кадәр һәр 7 эш көне саен, түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Туфрак тырмалауда эшләүче иң яхшы механизатор»;

«Бөртекле культуралар чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор»;

«Техник культуралар һәм кукуруз чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор».

2. Катнашучыларга түбәндәге таләпләр куела:

2.1. «Туфракны тырмалауда эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;
- югары егәрлеккә һәм 180 ат көченә (аерым) карап, авыл хуҗалыгы техникасын кулланып эшләр башкару;

2.2. «Бөртекле культуралар чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;
- чәчү комплексын яисә СЗ (СЗП) кулланып эшләр башкару (аерым-аерым);

2.3. «Техник культуралар һәм кукуруз чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;
- техник культуралар һәм кукуруз чәчкечләрен кулланып эшләр башкару.

3. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен түбәндәге составта конкурс комиссиясе төзергә:

Комиссия рәисе:

Кадыйров Н.К. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия әгъзалары:

Мусин Г.К. - Алексеевск муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча)

| | |
|---|---|
| Михайлов Ю.В. | - авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Поповнин В.В. | - Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Ибраһимова А.И. | - Алексеевск муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты (килешү буенча) |

4. Конкурсның һәр чорында катнашуга гаризалар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсендә alekseevsk.alsu@tatar.ru электрон рәвештә хисап чорының соңгы эш көнендә атна саен бирелә.

Җыелган гаризалар көн азагында конкурс комиссиясе рәисенә җибәрелә.

5. Комиссия утырышлары комиссия рәисе карары буенча атна саен уздырыла. Комиссия утырышы күпчелек әгъзалары катнашында тулы хокуклы дип санала. Җиңүче шунда катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән билгеләнә.

6. Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм алар арасында күмелгән һәм эшкәртелгән җир мәйданына бәйле рәвештә премияләр бүлә (файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының аерым төркемнәре буенча, куәтләренә карап, 180 ат көче):

1 урын - 2000 (ике мең) сум,

2 урын - 1500 (бер мең биш йөз) сум,

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм чәчелгән җир мәйданына карап (чәчү комплексын яисә СЗ (СЗП) аерым-аерым файдаланып) алар арасындагы премияләрне бүлә:

1 урын - 2000 (ике мең) сум,

2 урын - 1500 (бер мең биш йөз) сум,

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм алар арасындагы премияләрне, техник культуралар һәм кукуруз чәчелгән мәйданга карап, бүлә:

1 урын - 2000 (ике мең) сум,

2 урын - 1500 (бер мең биш йөз) сум,

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**